| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2021 Казан ш. № 461-128/кс-2021

«Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2021-2023 елларга эчә торган суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» ҖЧҖ) өчен 2021-2023 елларга эчә торган суга һәм ташландык су агызуга әлеге карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» ҖЧҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.
4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2021 № 461-128/кс-2021 карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» ҖЧҖ өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2022 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр |
| 1 | «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» ҖЧҖ | | | | |
| 1.1 | Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге кулланучылары | | | | |
| 1.1.1 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 41,45 | 41,52 | 28,85 | 30,64 |
| 1.1.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 34,54 | 34,60 | 24,04 | 25,53 |
| 1.2 | Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегеннән кулланучылар | | | | |
| 1.2.1 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | | | 47,12 | 47,44 |
| 1.2.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | | | 39,27 | 39,53 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге